РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Татарско-Шуганского сельского поселения Азнакаевского муниципального района
ул. Советская, д. 41в , село Татарский Шуган, Азнакаевского муниципального района, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай
муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советы
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 41в, Татар Шуган авылы Азнакай муниципаль районы, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» ноябрь 2024 ел №3

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. 2024 елның 12 ноябрь көнне Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Билгеләргә:
   - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Башкарма комитеты;
   - гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 12 ноябрь 2024 ел 11.00 сәг.тән 13.00 сәг.кадәр;
   - үткәрү урыны – Татар Шуганы авылы, Совет ур., 41б йорт;
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
   - 2024 елның 02 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы җирлеге Башкарма

комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Татар Шуганы авылы, Совет урамы, 41в йорт;

- сайлау хокукына ия булган Татар Шуганы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Татар Шуганы торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

4. «Сез, 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә җирле мәгънәдә гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Татар Шуганы авылы Яшьләр урамында юлларга вак таш җәю , сатып алу, ташу, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны, Татар Шуганы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык




М.Ш.Хәертдинов